СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 15-34 от «23» июня 2019 г.

«Татарстан Республикасы Мамадышмуниципаль районыОмар авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Мамадыш районы прокурорының 2019 елның 3 июнендәге 02-08-02-2019 санлы протесты, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Су кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 ел, 06 октябрь, 131 - ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районыОмар авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставынигезендә,Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы СоветыКАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Мамадыш муниципаль районы Советының 2018 ел, 19 ноябрь, 5-29 санлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районыОмар авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә" түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 30 статьяның 8 пунктындагы 39 абзацында «гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерцияле булмаган берләшмәләре» сүзләрен «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару»сүзләренә алмаштырырга.

2.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетына (Башкарма комитетның инфраструктур үсеш бүлегенә) әлеге карарны һәм «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен расланган көннән алып биш көн эчендә территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырырга.

3. Әлеге карарныһәм «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренМамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://mamadysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru).

000073

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының Җирле үзидарә, аграр сәясәт, җирдән файдалану һәм экология буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,<br>муниципаль район<br>Советы рәисе — А.П.Иванов